ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь, 2019 ел № 33/7

Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

2019 елның 5 апрелендәге «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 9 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 63-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 22 октябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2/11 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/8, 2018 елның 08 ноябрендәге 27/7санлы Карары редакциясендә), 4 пункттагы 10 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Сайлап алынган салым ташламасы бирелә торган салым объектлары турында язмача хәбәр, салым түләүченең теләге буенча, әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланылучы салым чоры булып торган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, салым җыю органына тапшырыла.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев